**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасының «Россия» халыкара күргәзмә-форумында катнашуын әзерләү буенча оештыру комитеты төзү турында**

Россия Федерациясе Президентының «Россия» халыкара күргәзмә-форумын әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитеты турында» 2023 елның 29 мартындагы 215 номерлы Указы нигезендә, 2023–2024 елларда Мәскәү шәһәрендә Халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсе территориясендә уздырыла торган «Россия» халыкара күргәзмә-форумында Татарстан Республикасының катнашуын әзерләгәндә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарының, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарының, оешмалар һәм иҗтимагый берләшмәләрнең үзара хезмәттәшлеген оештыру максатларында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасының «Россия» халыкара күргәзмә-форумында катнашуын әзерләү буенча оештыру комитеты төзергә.

2. Татарстан Республикасының «Россия» халыкара күргәзмә-форумында катнашуын әзерләү буенча оештыру комитеты турында нигезләмәне (1 нче кушымта) һәм аның составын (2 нче кушымта) расларга.

3. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2023 ел, 29 июль
№ 520

Татарстан Республикасы
Рәисенең
2023 елның «29» июлендәге
520 номерлы Указына
1 нче кушымта

**Татарстан Республикасының «Россия» халыкара күргәзмә-форумында катнашуын әзерләү буенча оештыру комитеты турында нигезләмә**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Татарстан Республикасының «Россия» халыкара күргәзмә-форумында катнашуын әзерләү буенча оештыру комитеты (алга таба тиешенчә – Оештыру комитеты, Күргәзмә) – Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарының (алга таба – федераль башкарма хакимият органнары территориаль органнары), Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнарының (алга таба – җирле үзидарә органнары), оешмалар һәм иҗтимагый берләшмәләрнең Татарстан Республикасының Күргәзмәдә катнашуын әзерләгәндә үзара хезмәттәшлеген оештыру максатларында төзелгән коллегиаль орган.

2. Оештыру комитеты үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль конституциячел законнарга, федераль законнарга, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

## II. Оештыру комитетының төп бурычлары

3. Оештыру комитетының төп бурычлары түбәндәгеләр:

а) Татарстан Республикасының Күргәзмәдә катнашуын әзерләү буенча республика чаралар планын төзү һәм раслау;

б) Татарстан Республикасының Күргәзмәдә катнашуын әзерләү белән бәйле планнарны, программаларны һәм аерым чараларны гамәлгә ашыру барышын анализлау, Татарстан Республикасының Күргәзмәдә катнашуын әзерләү буенча республика чаралар планы үтәлешен һәм аны гамәлгә ашыруга бүлеп бирелгән финанс чараларыннан максатчан файдалануны контрольдә тотуны тәэмин итү;

в) Оештыру комитеты кабул иткән карарларны гамәлгә ашыру һәм аларның нәтиҗәлелеген бәяләү барышында Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының, федераль башкарма хакимият органнары

территориаль органнарының, җирле үзидарә органнарының, оешмалар һәм җәмәгать берләшмәләренең үзара хезмәттәшлеген оештыру буенча тәкъдимнәр эшләү;

г) Татарстан Республикасының Күргәзмәдә катнашуын әзерләү буенча республика чаралар планын үтәүгә бәйле бурычларны хәл иткәндә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының, федераль башкарма хакимият органнары территориаль органнарының, җирле үзидарә органнарының, оешмаларның һәм иҗтимагый берләшмәләрнең үзара хезмәттәшлеген оештыру.

4. Оештыру комитеты үз алдында торган бурычларны хәл итү максатларында түбәндәгеләргә хокуклы:

а) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарыннан, федераль башкарма хакимият органнары территориаль органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, оешмалардан һәм иҗтимагый берләшмәләрдән законнар нигезендә Оештыру комитеты компетенциясенә кагылышлы мәсьәләләр буенча мәгълүмати материаллар соратып алырга;

б) билгеләнгән тәртиптә Оештыру комитеты компетенциясенә кагылышлы мәсьәләләрне хәл итү өчен эш төркемнәре төзергә;

в) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнары территориаль органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар, иҗтимагый берләшмәләр җитәкчеләрен, аларның башка вәкилләрен һәм кызыксыну белдергән бүтән затларны билгеләнгән тәртиптә үз утырышларына чакырырга;

г) үз вәкилләрен Татарстан Республикасының Күргәзмәдә катнашуын әзерләү мәсьәләләре буенча киңәшмәләрдә, конференцияләрдә һәм семинарларда катнашырга җибәрергә.

## III. Оештыру комитеты составы

5. Оештыру комитеты составын Татарстан Республикасы Рәисе раслый.

6. Оештыру комитеты составына аның эшендә иҗтимагый башлангычларда катнашучы Оештыру комитеты рәисе, рәис урынбасарлары, секретаре һәм башка әгъзалары керә.

7. Оештыру комитеты рәисе булып Татарстан Республикасы Премьер-министры тора.

8. Оештыру комитеты рәисе:

а) Оештыру комитеты эшенә җитәкчелек итә, Оештыру комитеты утырышлары мәсьәләләре исемлеген, аларны карап тикшерү срокларын һәм тәртибен билгели;

б) урынбасарлары һәм Оештыру комитеты әгъзалары арасында вәкаләтләрне (вазыйфаларны) бүлә;

в) көн тәртибен, утырышларны үткәрү датасын, урынын һәм вакытын билгели һәм раслый;

г) үзе эш урынында булмаган вакытта урынбасарларының берсен Оештыру комитеты рәисе вазыйфаларын башкаручы итеп билгели;

д) Оештыру комитеты утырышлары беркетмәләренә һәм башка документларга кул куя.

9. Оештыру комитеты секретаре:

а) Оештыру комитеты утырышларында катнаша;

б) Оештыру комитеты әгъзаларына утырыш уздырыласы көнгә кадәр кимендә биш көн алдан утырышны уздыру урыны, датасы, вакыты турында хәбәр итә, утырышның көн тәртибен юллый;

в) Оештыру комитеты утырышлары беркетмәләрен һәм башка документларын әзерләү өчен җавап бирә.

10. Оештыру комитеты әгъзалары:

а) Оештыру комитеты утырышларында шәхсән катнаша;

б) Оештыру комитеты компетенциясендәге мәсьәләләр буенча тәкъдимнәрне фикер алышуга куя;

в) Оештыру комитеты карарларын әзерләү, үтәү буенча башка чараларны гамәлгә ашыра.

## IV. Оештыру комитеты утырышлары һәм карарлары

11. Оештыру комитеты утырышлары ихтыяҗ туган саен, әмма кимендә кварталга бер тапкыр үткәрелә.

12. Оештыру комитеты утырышларын рәис яисә аның кушуы буенча рәис урынбасарларының берсе алып бара.

13. Оештыру комитеты утырышы, әгәр анда әгъзаларының яртысыннан күбрәге катнашса, эшчәнлек алып барырга хокуклы дип санала. Оештыру комитеты карары, әгәр аның өчен утырышта катнашкан әгъзаларының яртысыннан да ким булмаган өлеше тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала. Тавышлар саны тигез булган очракта, рәислек итүченең тавышы хәлиткеч була. Оештыру комитеты утырышында көн тәртибендәге мәсьәләләрне карап тикшерү һәм тавыш бирү йомгаклары буенча карарлар кабул ителә, алар беркетмә белән рәсмиләштерелә. Оештыру комитеты утырышы беркетмәсенә рәислек итүче кул куя.

14. Оештыру комитеты тарафыннан кабул ителгән карарлар Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең кызыксынган органнарына, федераль башкарма хакимият органнары территориаль органнарына, җирле үзидарә органнарына, оешмаларга һәм иҗтимагый берләшмәләргә, кызыксыну белдергән бүтән затларга эшчәнлек алып барганда куллану өчен җиткерелә.

## V. Оештыру комитеты эшчәнлеген тәэмин итү

15. Оештыру комитеты эшчәнлеген матди-техник яктан, документлар, мәгълүмат белән һәм башкача тәэмин итүне Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы башкара.

Татарстан Республикасы
Рәисенең
2023 елның «29» июлендәге
520 номерлы Указына
2 нче кушымта

**«Россия» халыкара күргәзмә-форумында Татарстан Республикасының катнашуын әзерләү буенча оештыру комитеты составы**

| | |
|---|---|
| Песошин Алексей Валерьевич | Татарстан Республикасы Премьер-министры, Оештыру комитеты рәисе |
| Коробченко Олег Владимирович | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры, Оештыру комитеты рәисе урынбасары |
| Фазлыева Ләйлә Ринат кызы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, Оештыру комитеты рәисе урынбасары |
| Миңнуллина Талия Илгиз кызы | Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы җитәкчесе, Оештыру комитеты секретаре |
| Әхмәтшин Равил Кәлимулла улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Россия Федерациясендә Татарстан Республикасының Тулы вәкаләтле вәкиле |
| Әюпова Ирада Хафизҗан кызы | Татарстан Республикасы мәдәният министры |
| Власов Руслан Игоревич | «ИТ-парк» югары технологияләр өлкәсендәге технопаркы» дәүләт автоном учреждениесе директоры (килешү буенча) |
| Габдрахманова Гөлнара Зәкәрия кызы | Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты рәисе |
| Гайзатуллин Радик Рәүф улы | Татарстан Республикасы финанс министры |

| | |
|---|---|
| Зарипова Эльмира Әмир кызы | Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры |
| Җәббаров Марат Азат улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры |
| Иванов Сергей Евгеньевич | Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты рәисе |
| Леонов Владимир Александрович | Татарстан Республикасы спорт министры |
| Миңнуллин Марсель Мансур улы | Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры |
| Мөхәрләмов Руслан Роберт улы | Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы Рәисенең Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты җитәкчесе |
| Насыйбуллин Назил Наил улы | Татарстан Республикасы Премьер-министрының тышкы икътисадый эшчәнлек буенча ярдәмчесе |
| Савельев Игорь Леонидович | Татарстан Республикасы Президенты Администрациясе Җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы Президентының Эксперт департаменты җитәкчесе |
| Садыйков Ринат Наил улы | Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министры |
| Сәлимгәрәев Айдар Сәетгәрәй улы | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе |
| Сафин Ленар Ринат улы | «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесе ректоры, Татарстан Республикасы югары уку йортлары ректорлары советы рәисе (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Семенихин<br>Кирилл Владимирович | «Иннополис университеты» югары белем бирү автоном коммерциячел булмаган оешмасы директоры (килешү буенча) |
| Һадиуллин<br>Илсур Гәрәй улы | Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры |
| Хәйруллин<br>Айрат Ринат улы | Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министры |
| Хәлимов<br>Ренат Азат улы | «Иннополис» махсус икътисадый зонасы» акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Хәнифов<br>Фәрит Мөдәррис улы | Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министры |
| Шаһивәлиев<br>Тимур Наил улы | «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Шаһиәхмәтов<br>Мидхәт Рәфкать улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы икътисад министры |
| Шәйхразиев<br>Васил Габделгаяз улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары |
| Шәйхетдинов<br>Роман Александрович | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары |

______